**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2022елнын 05 декабре** **96-РС номер**

# К А Р А Р

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 09 апрелендәге 25-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары , муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә Лаеш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 9 апрелендәге 25-РС номерлы карары белән расланган җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына (Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарлары үзгәрешләре белән № 58-РС 08.09.2020 ел, № 92-РС 29.11.2021 ел, № 3-РС 31.01.2022 ел1әм № 75-РС 10.10.2022 ел.) үзгәрешләр кертергә:

- 1 пунктта «11 958» санын «12 688» санына алмаштырырга;
- 8 пунктның 5 пунктчасында «1 процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга»;
- «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру» 2 өлешнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент " сүзләренә алмаштырырга»;
- 2 нче кушымтаны күрсәтелгән карарга яңа редакциядә бәян итәргә (беркетелә).

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советының
2022 елның 5 декабрендәге
96-РС номерлы карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының контроль-хисап органы рәисләренең айлык акчалата хезмәт хакы күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 33 592 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 30 233 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 30 233 |